**Нурмөхәммәтова Р.С.,**
**Казан федераль университеты**

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ «РИЗЫК АТАМАЛАРЫ» ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ТӨРКЕМЕНДӘ ГОМУМТӨРКИ ТАМЫРЛЫ СҮЗЛӘР

Аннотация. Основу лексического фонда татарского языка составляют слова, которые встречаются во многих близкородственных тюркских языках. Данная статья посвящается изучению лексических единиц с общетюркскими корнями лексико-семантической группы “пища”.

Ключевые слова: татарский язык, лексико-семантическая группа, общетюркская основа, названия пищи

Һәрбер телнең сүзлек составында элек-электән кулланылып килгән, шул ук вакытта башка телләрдә дә очрый торган бер төркем сүзләре була. Тамырлары белән борынгы баба телгә барып тоташа торган әлеге сүзләр, гадәттә, телнең нигез ташларын тәшкил итә.

Төрки телләр лексикасының төп өлеше шулай ук борынгыдан килә, еш кына сүзләрнең параллельләре башка алтай телләрендә дә күзәтелә. Мондый берәмлекләр күбрәк сүзлек составының элек-электән формалашып, хәзерге көндә дә тотрыклылыгын һәм актуальлеген саклаган лексик-семантик төркемнәрендә күбрәк очрый. Халыкның ашау-эчү традицияләре нәкъ менә шундый катламны тәшкил итә. Шунлыктан аш-су атамалары арасында бер төркем сүзләр күпчелек кардәш һәм кардәш булмаган халыкларда очрый. Әлбәттә, бу берәмлекләр төрле этносларның озак еллар аралашып яшәве нәтиҗәсендә бер-берсенә үтеп керергә, ягъни алынмалар булырга да мөмкин. Тик шулай да уртак тарихка ия халыкларда борынгы төрки телдән үк килә торган сүзләрнең булуы инде тарихи яктан расланган факт.

Бу хезмәттә без татар телендә бүгенге көндә актив кулланылышта булган гомумтөрки тамырлы аш-су атамаларының кайберләренә тукталып үтүне максат итеп куябыз.

Ризык – теләсә кайсы этносның матди мәдәниятендә иң мөһим һәм борынгы компонентларның берсе. Аның үзенчәлеге иҗтимагый-икътисадый шартлар, буыннар хәтере, күпсанлы этник багланышлар белән билгеләнә. Ашау-эчү белән бәйле традицияләр замана йогынтысына үтә сизгер булсалар да, даими үзгәреп торган чынбарлыкка яраклаша алулары белән аерылып торалар. Ризыклардагы компонентлар үзгәрергә, хәзерләү шартлары камилләшергә мөмкин. Әмма халыкның аларга булган мөнәсәбәте, бу ашамлыкларның кешеләрнең туклану ихтыяҗын канәгатьләндерә алу сыйфаты тотрыклы кала. Шул сәбәпле әлеге аш-су атамалары телнең лексикасында төп урынны алып тора да инде.

Татар telendә килеп чыгышлары белән борынгы төрки телдән килгән ризык атамалары шактый. Без бу очракта матди мәдәният элементлары буларак каралган, ягъни кеше тарафыннан эшкәртелеп кулланыла торган ризыкларны атый торган берәмлекләрне генә күздә тотабыз. Алар тамыр хәлләрендә дә, башка сүзләр составында да яшәргә мөмкин.

Иң элек ризык мәгънәсен гомумиләштереп атый торган сүзләргә күз салыйк. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә (алга таба – ТТАС) «ашау-эчү әйберләре, ашамлык әзерләүгә китә торган нәрсә; ашамлык, ашарга әзерләнгән нәрсәләр» (ТТАС, 26) мәгънәсендә теркәлгән **азык** сүзе, Р.Әхмәтьяновның «Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге»ндә бирелгән мәгълүмат буенча (алга таба – ТТКТЭС), гомумтөрки *азык, азук* «азык; ашамлык запасы» сүзеннән килә. Бу сүз алтай, казакъ телләрендә шулай ук *азык*, уйгур телендә *озук*, якут телендә *йысык* рәвешендә сакланган; борынгы язмаларда *азук* «азык, азык-төлек» мәгънәсендә очрый [ТТКЭС, 11].

«Ашау өчен махсус хәзерләнгән нәрсә: ашамлык, азык, ризык» [ТТАС, 59] мәгънәсендәге **аш** сүзе дә гомумтөрки *аш* «аш, ашамлык; иген, икмәк, арпа» сүзеннән дип уйланыла [ТТКТЭС, 24].

**Бавырсак** – чикләвек зурлыгында ваклап, майда кайнатып пешерелә торган милли камыр ризыгы [ТТАС, 64]. Гомумтөрки телдәге *баўрсак, боғурсак*

«бавырсак, вак кына туралган ит» дигәнне аңлата; монгол телендә *буурцаг* «бавырсак, борчак» сүзе бар [ТТКТЭС, 31].

**Казылык** (эчәккә яки ясалма элпәгә тутырып махсус эшләнгән ит фаршы һ.б.ш.) [ТТАС, 222] гомумтөрки *казы* «казы, эчмай, казылык» сүзеннән, борынгы **кар* тамырыннан [ТТКТЭС, 86]. Чуваш телендә *йур* «казы», бурятча *харма* «казылык, колбаса», монголча *карбиӊ* «корсак мае» мәгънәләрендә сакланган.

Сөтнең өстенә җыела торган куе, майлы өлеше хәзерге татар телендә **каймак** дип атала [ТТАС, 222]. Бу атама гомумтөрки *каймак* «каймак, өре» сүзеннән, борынгы *кай-* «кайнау» фигыленнән ясалган (*каймак* сүзенең беренчел төп мәгънәсе – кайнап суынган сөт яки шулпаның өстенә җыелган, яки савыт стеналарына утырган тәмле өресе) [ТТКТЭС, 87]. Борынгы болгар телендә *ҫайаҫ* «май, каймак» дигәнне белдергән; көнчыгыш төрки телләрдә *эт каймагы* «ит шулпасы», якут телендә *хоймох* «сөт төбе (кайнаганда төпкә утырган сөт)», монгол телендә *кайы-мак, хайлмах* «каймак» сүзләре кулланылышта йөри.

**Как** – җиләк-җимешне изеп, юка гына җәеп кояшта яки мич кызуында киптереп ясалган әчкелтем чәй ашамлыгы [ТТАС, 224]. Гомумтөрки телдә *как* «коры, кипкән, каты кипкән җир, киптерелгән җимеш яки җимеш измәсе» кебек мәгънәләрне белдергән [ТТКТЭС, 87-88]. Бу тамыр *как* (коры, корыган, артык нык кипкән; каты), *каклаган* (махсус юл белән киптерелгән), *каклану* (кибү), *каклау* (ит, балык һ.б. киптерү) кебек сүзләрдә сакланган. Бу нигездән ясалган татар халкының затлы ризыгы *каклаган каз* – махсус ысул белән киптереп әзерләнгән каз. Златоус, минзәлә, бугуруслан сөйләшләрендәге как мәгънәсендә йөри торган *кагыт* шулай ук әлеге тамырдан дип уйланыла [Татар теленең зур диалектологик сүзлеге, 374].

**Калач** татар телендә ак күмәчне белдерә [ТТАС, 224]. Бу сүзнең дә төбендә борынгы төрки сүз дип уйланыла: борынгы төрки телдә *кäлäч*; борынгы рус телендә *колач* «калач, түгәрәк ипи» мәгънәсендә кулланылган; чувашча *холач, хулаç,* мари, удмурт, үзбәк телләрендә *калач, кäлäч* дип әйтелә;

гомумтөрки телдә *калач, калас, калаш* вариантларында очрый; борынгы кыпчак телендә *калач* «уртасы тишекле (бауга тезмәле) ипи»не атау өчен йөргән [ТТКТЭС, 88].

Татар халкының милли сөт ризыгы саналган **катык** – кайнатылган сөткә оеткы салып ясалган (оетылган) ашамлык [ТТАС, 242]. «Ашка катыла, кушыла торган нәрсә»не аңлаткан гомумтөрки *катық* < *катығ* сүзе – гомумтөрки *кат-* «кушу» фигыленнән ясалган; *қатық* борынгы уйгур телендә «аш серкәсе»н, борынгы төрки телдә «аш тәмләткеч»ен белдергән; гагауз телендә әлеге сүз «өстәмә ризык»ны, тува телендә *кадыг* «бутка», азәрбәйҗан диалектларында *гатых* «соус»ны аңлата [ТТКТЭС, 95].

**Коймак** – сыек камырны кызган табада коеп пешергән ашамлык [ТТАС 2005, 265]. Аңлатмадан күренгәнчә, ризык атамасы *кою* фигыленә *-мак* кушымчасы өстәлеп ясалган, гомумтөрки телдә әлеге фигыль *куй-* рәвешендә булган дип санала. Бу сүз күп телләрдә очрый: удмурт, мари телләрендә *куймак*, чуваш теле диалектларында *каймак, куймак* һ.б. [ТТКТЭС, 110].

**Корыт** – 1) әчегән сөтне, катыкны сөзеп һәм киптереп ясалган каты ашамлык (запас азык-төлек буларак кулланылган); 2) кызгылт-сары төстәге коры эремчек (ул көпшәк, ярмасыман була) [ТТАС, 284]. Әдәби телдә *корт* фонетик варианты активрак йөри [ТТАС, 282]. *Корыт* – гомумтөрки *курут*, куру- «кору, кибү» сүзеннән дип карала [ТТКТЭС, 88]. Бу ризыкны *тура* (эремчекне кызарганчы кайнатып ясалган ашамлык; корт) [ТТАС, 566] дип тә йөртәләр. Җамал Вәлиди сүзлегендә тура «تورا – (чагатайда “тура” – сыр, чуашда “тура” – катык) – эремчекдән ясалган корт (лаеш)» [Вәлиди 1929, 619-620] дип теркәлгән. Өйдә әзерләнгән сыр мәгънәсендәге *тура* сүзе мари, удмурт, татар диалектларында *туара*, чувашча *тăвара, турах, торах,* чыгтай телендә *торақ*, монголча *тараг* вариантында да очрый [ТТКТЭС, 213]. Татар телендәге *турта* – атланмайны эреткәндә барлыкка килә торган эремчеккә охшаш куе утырма [ТТАС, 567] сүзе дә шушы тамырдан булырга мөмкин.

**Талкан** сүзенең хәзерге татар телендәге аңлатмасы – кайнатып киптерелгән ашлыкның эре онынннан суда болгатып әзерләнгән ашамлык

[ТТАС, 511]. Бу ризык хәзер татар халкында әллә ни популяр түгел, чөнки ул, шактый еллар дәвамында Җ.Вәлиди аңлатканча, «تالقان – ондан болгатыб ясалган бер төрле аш – ярлылар ашы» [Вәлиди 1929, 567] буларак кабул ителде. Тик соңгы елларда ризыкка караш үзгәрү аның яңадан табынга кире кайта башлавына китерде. Талкан сүзенең килеп чыгышын Р.Әхмәтьянов түбәндәгечә аңлата: гомумтөрки *талкан, талган* «талкан, он, онтак» мәгънәсендә йөргән; гомумтөрки *талкы-у* «ваклау, онтау» сүзеннән [ТТКТЭС, 189]. Җ.Вәлиди дә сүзнең этимологиясенә берникадәр ачыклык керткән: «талкан»ның русча «толокно»дан бозылган булуы ихтималы юк. Чөнки бу көнчыгыш шивәләрендә һәм борынгы чыгатайда да шул хәлдә бар. Ул изү, ваклау мәгънәсендә булган «талку» фигыле белән бер төбдән. Бу «Диван лөгат эттөрек»дә дә бар, дип яза [Вәлиди 1929, 567].

Тапалган ит белән ярма катнашмасын кәбестә яфрагына төреп, я яшел борыч эченә тутырып хәзерләнгән ашамлык татар телендә **тулма** дип йөртелә [ТТАС, 563]. Кайбер халыкларда бу ризык йөзем [виноград] яфрагына төреп хәзерләнә. Төрек телендә – *долма*; аны дол- «тулу» сүзеннән дип уйлыйлар; ләкин гагауз телендә *долма* борынгы дол-, тол- «урау» сүзенә барып тоташа дигән фикер дә бар [ТТКТЭС, 110].

**Умач**, ягъни онны су, ит шулпасы яки сөт белән катнаштырып уып, ашка салу өчен ясалган ашамлык, вак-вак камыр кисәкләре [ТТАС, 609] атамасы да гомумтөрки у-, оғ- «уу» сүзеннән дип уйланыла [ТТКТЭС, 219]. Җ.Вәлиди бу ризыкка түбәндәгечә аңлатма бирә: «ئوماچ – камырдан уыб пешерелгән шулпалы аш. Күбесенчә итсез пешерелә һәм ачлык елларында арыш камырыннан уылыб яки суррогатлар катышдырылыб пешерелә торган фәкыйрьләр ашы» [Вәлиди 1927, 222]. Әлеге ризыкны хәзер татар халкы бик пешерми, шулай да атама күп кенә төрки телләрдә дә сакланган: казакъ телендә *умаҗ*, чыгтай, үзбәк телләрендә *умач, омоч*, госманлы телендә *омаҗ, огмаҗ* [ТТКТЭС, 219].

Шул рәвешчә, хәзерге татар телендә кулланылышта булган һәм татар халкының туклану үзенчәлекләрен тәшкил иткән сүзләрнең шактые борын-

борыннан сакланып килә, тамырлары белән алар гомумтөрки телгә барып тоташа.

Файдаланылган әдәбият

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы сүзлеге. 1 т. 1 кисәк. – Казан: Татарстан мәгариф комиссариатының гыйльми үзәге басмасы, 1927. – 352 б.

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы сүзлеге. 1 т. 2 кисәк. – Казан: Татарстан мәгариф комиссариатының гыйльми үзәге басмасы, 1929. – 353-720 б.

Татар теленең этнокультура сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (сүзлек-белешмәлек) / Төзүче авторлар: Р.Р.Җамалетдинов, Р.С.Нурмөхәммәтова. – Казан: Отечество, 2012. – 146 б.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.